КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 30 июль г.Казань № б-1431

1. «Чиста ил» калдыклар белән эш итү өлкәсендәге оешмалар, операторлар һәм белгечләр ассоциациясенең 2021 елның 20 сентябрендә Казан шәһәрендә коммуналь техниканың «Чиста ил 2.0» икенче бөтенроссия автомобильләр ярышы кысаларында чаралар (алга таба – чаралар) үткәрү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. 2021 елның 20 сентябрендә Казан шәһәрендә коммуналь техниканың «Чиста ил 2.0» икенче бөтенроссия автомобильләр ярышы кысаларында чаралар үткәрү буенча оештыру комитетын төзергә һәм аның составын (боерыкка теркәлә) расларга.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына чаралар үткәрү урыннарында катнашучыларга шартнамә нигезендә медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында чаралар әзерләү һәм үткәрү барышын яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, проектның амбассадорын җәлеп итеп, мәктәп укучылары өчен экологик культураны һәм грамоталыкны арттыруга юнәлдерелгән экологик дәресләр үткәрүне тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына ихтыярый (волонтерлык), яшьләр иҗтимагый оешмаларын һәм студентларны чаралар үткәрүгә җәлеп итүдә ярдәм күрсәтергә.

7. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, спортчыларны, йөгерү берләшмәләрен, яшьләрне җәлеп итеп, 2 км дистанциягә плоггинг (йөгереш) уздыруны тәэмин итәргә.

8. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына концерт һәм күңел ачу программасын оештыруны тәэмин итәргә.

9. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына чараларны үткәрү урыннарында аларны оештыручыларга хокук тәртибен саклауны һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына чараларны әзерләүдә һәм үткәрүдә аларны оештыручыларга ярдәм күрсәтүне;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә чараларда катнашучыларның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү максатларында тиешле чаралар үткәрүне тәэмин итүне;

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә чараларны үткәрү урыннарында янгын куркынычсызлыгы чаралары үтәлешенә күзәтчелекне тәэмин итүне.

10. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 30 июль, б-1431 нче
боерыгы белән расланды

2021 елның 20 сентябрендә Казан шәһәрендә коммуналь техниканың «Чиста ил 2.0» икенче бөтенроссия автомобильләр ярышы кысаларында чаралар үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, оештыру комитеты рәисе |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Гафаров Рөстәм Гыйльфан улы | Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Габдерахманов Ленар Ринат улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Кашапов Айдар Ринат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе баш киңәшчесе |
| Леонов Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры |
| Мөхәммәтҗанов Фәргать Госман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Садыйков Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Трофимова Марина Викторовна | Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Фәйзетдинова Гөлназ Рәис кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары секретариаты баш киңәшчесе |
| Фәттахов Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Хәбибуллин Рафис Җәүдәт улы | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Шәвәлиев Рөстәм Хәйдәр улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе баш киңәшчесе |
| Шадриков Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры. |

________________________________